**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ К А Р А Р

от ______________ ПР-162 22.07.2026 № ________

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Бала туганда бер мәртәбә түләү турында» 2026 елның 08 апрелендәге ПР-89 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты
**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Бала туганда бер мәртәбә түләү турында» 2026 елның 08 апрелендәге ПР-89 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктында «бала» сүзләреннән соң «комиссия составы»сүзләрен өстәргә.

1.2. Нигезләмәнең 2 пунктында «хөкем ителүе булмаган» сүзләрен тошереп калдырырга.

1.3. 6, 7, 8 пунктларны яңа редакциядә бәян итәргә:

«6. Бала туганда бер мәртәбә түләүне билгеләү өчен әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнар яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә, алар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар (алга таба - мөрәҗәгать итүчеләр) Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлегенә тапшыралар:

- банкта яисә башка кредит оешмасында ачылган счет реквизитларын күрсәтеп, бала туганда бер мәртәбә түләү билгеләү турында гариза (алга таба-гариза);
- әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;
- вәкаләтле затлар өчен ышанычнамә күчермәсе;
- бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр;
- ананың үлемен дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр;
- опека (попечительлек)билгеләү турында белешмәләр;
- ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителү яисә ата-ана хокукларын чикләү турында белешмәләр;
- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычларның булмавы турында белешмәләр.

Мөрәҗәгать итүчеләр гариза белән мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документны күрсәтәләр. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында

билгеләнгән тәртиптә таныкланырга тиеш. Актаныш районында яшәү факты паспорт белән раслана.

7. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты гариза теркәлгән көннән алып 30 календарь көн эчендә комиссия утырышында документлар пакетын карый һәм бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү турында яисә аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә. Карар Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәсе белән рәсмиләштерелә. Кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән хәбәр ителә.

8. Берьюлы бердән артык бала туган очракта, туган һәр балага бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирелә».

1.4. Комиссия составын яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.М. Әнвәровага йөкләргә.

Җитәкче И.Ш. Бариев

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карары
____________ ______ №____
белән расланган

КОМИССИЯ* СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Бариев Илфак Шамил улы | - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Сираева Лиана Рамил кызы | - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Шәехова Ильвира Марс кызы | - Актаныш муниципаль районы Советы баш бухгалтеры, комиссия секретаре; |
| Вахитов Илшат Рәфит улы | - Актаныш районы Советы Аппараты җитәкчесе; |
| Әнвәрова Дилбәр Миркасыйм кызы | - Актаныш районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары; |
| Мөхәмәдиева Гөлфинә Баян кызы | - Актаныш муниципаль районы граждан хәле актларын теркәү бүлеге башлыгы; |
| Корбангалина Алиса Айрат кызы | - Актаныш муниципаль районы «Финанс-бюджет палатасы» МКУ рәисе; |
| Гилаева Миләүшә Зөфәр кызы | - Актаныш муниципаль районы оештыру бүлеге башлыгы; |
| Сәрвәрова Наилә Фәрит кызы | - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге җитәкчесе; |
| Хәев Айдар Рәфкать улы | - "Актаныш РҮХ" ДАССУ баш табибы; |
| Басыров Булат Мөзәллиф улы | - РФ пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды бүлекчәсенең Актаныш районындагы клиент хезмәте җитәкчесе (төркем хокукларында); |
| Хуҗәхмәтова Гөлназ Фирдәвис кызы | - ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Актаныш муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы; |
| Мөхәмәтдинов Илнар Тәлгать улы | - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы; |
| Шакирова Раниза Митҗан кызы | - Актаныш муниципаль районы «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы; |

*Искәрмә: Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә турыдан-туры буйсынмаган комиссия әгъзалары килешү буенча комиссия составына кертеләләр

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә гариза-ризалык

Мин,______________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

адресы буенча яшәүче: _____________________________________________,
(шәхесне таныклый торган документ: ______________, сериясе ______ номеры
_______,

бирелгән _______________________________________________________)

(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә, бала туганда бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләүне билгеләү максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына автоматлаштыру чараларын кулланып яисә мондый чараларны кулланмыйча башкарыла торган теләсә нинди гамәлне (операцияне), җыюны, язуны да кертеп, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), чыгару, куллану, тапшыру (тарату), минем шәхси мәгълүматларымны (белешмәләрне) һәм балигъ булмаган балаларымның шәхси мәгълүматларын (белешмәләрне) бирү, аларга керү), шәхессезләндерү, бетерү, юк итүгә ризалыгымны бирәм.
______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
_____________________________________________________________
фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, гаилә хәле, паспорт мәгълүматлары, теркәлү һәм яшәү урыны адресы, контактлы телефон номеры.

Югарыда күрсәтелгән органнар тарафыннан минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртү «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге №152-ФЗ Федераль закон таләпләренә тулысынча туры китереп башкарыла.

________________ ____________________ / ____________________/

Дата ФИА Имза